# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

1 статья. «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, №11) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяда:

дүртенче абзацка түбәндәге сүзләрне өстәргә: «әлеге Закон нигезендә дәүләт ярдәме гамәлләренең дәүләт заказчысы буларак,»;

түбәндәге эчтәлектә яңа абзац өстәргә:

«вәкаләтле оешма — вәкаләтле дәүләт органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме гамәлләрен үтәүче итеп билгеләнүче коммерциячел булмаган оешма».

2. Түбәндәге эчтәлектә яңа $1^1$ статья өстәргә:

«$1^1$ статья. Вәкаләтле оешманың эшчәнлек тәртибе

Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме гамәлләрен әлеге Закон нигезендә башкаручы вәкаләтле оешманың эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаучы нигезләмә белән билгеләнә.

Вәкаләтле оешма вәкаләтле дәүләт органы белән районнарның, шәһәрләрнең администрацияләре арасында төзелүче шартнамәләр нигезендә эш итә, әлеге шарнамәләрдә торак шартларын яхшыртуда яшь

353

гаиләләргә дәүләт ярдәме гамәлләрен үтәү буенча якларның үзара хокуклары һәм бурычлары билгеләнә.

Вәкаләтле оешма шартнамә яклары исеменнән яшь гаиләләр белән торак бинаны сату-алу, алмаштыру турында шартнамәләр, торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү гамәлләрен үтәү кысаларында бүтән төрле шартнамәләр төзи, күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның буенча алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алганда законнарда билгеләнгән тәртиптә катнаша.».

3. 6 статьяның исемендә һәм беренче өлешендә «финанслау» сүзен «күрсәтү» сүзенә алмаштырырга.

4. 7 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. Яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү

Үзенә карата дәүләт ярдәме күрсәтелү турында карар кабул ителгән яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләү граждан законнары нигезендә вәкаләтле оешма белән яшь гаилә арасында төзелүче торак бинаны сату-алу яисә алмаштыру шартнамәсе буенча башкарыла.

Торак бинаны сату-алу шартнамәсе сатып алына торган торак урыны өчен түләүне 15 елдан да артык булмаган вакытка кичектереп тору, башлангыч кертем түләүнең һәм яшь гаиләнең үз бурычларын үтәүне тәэмин итүенең мәҗбүрилеге шартларында төзелә. Сатып алына торган торак бина өчен яшь гаиләгә түләүне кичектереп торган өчен процентлар алынмый.

Алмаштыру шартнамәсе буенча яшь гаиләгә торак бинаны реализацияләгәндә, яшь гаилә аның буенча үзенең торак урынын сатып алына торганына алмаштыру өчен тапшырырга йөкләмә ала, бәяләрдәге аерманы яшь гаилә, процентлар түләмичә генә, түләүне 15 елга кадәр кичектереп тору шартнамәсе нигезендә түли.

Торак бинаны сату-алу яисә алмаштыру шартнамәсе буенча башлангыч кертем сатып алына торган торак урыны хакының кимендә 20 проценты күләмендә алына һәм ул акчалата һәм (яисә) яшь гаиләнең милекчелек хокукындагы торак урыны белән гамәлгә ашырыла.

Әлеге статья нигезендә төзелүче шартнамәдә, әч яшькә кадәрге баласы булган яшь гаилә гаризасы буенча, балага өч яшь тулганчы түләүләрне кичектереп тору шартлары каралырга тиеш.».

354

5. 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. Яшь гаилә өчен торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүне тәэмин итү

Яшь гаилә өчен торак бинасын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүне тәэмин итү вәкаләтле оешма белән яшь гаилә арасында граждан законнарына туры китереп төзелүче шартнамә нигезендә башкарыла, анда яшь гаиләгә торак урынын төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерү өчен кирәк булган товарларны сату, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү каралырга мөмкин.

Торак бинаны төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетерүне тәэмин итү турында шартнамә сатып алынучы товарлар, башкарылучы эшләр, күрсәтелүче хезмәтләр өчен түләүне 15 елдан да артык булмаган вакытка кичектереп тору һәм яшь гаиләнең үз бурычларын үтәүне тәэмин итүенең мәҗбүрилеге шартларында төзелә. Сатып алынучы товарлар, башкарылучы эшләр, күрсәтелүче хезмәтләр өчен түләүне кичектереп торган өчен процентлар алынмый.

Әлеге статья нигезендә төзелүче шартнамәдә торак бинаны төзеп һәм (яисә) реконструкцияләп бетергәнче түләүләрне кичектереп тору шартлары каралырга тиеш, әмма ул вакыт тугыз айдан да артык була алмый.

Әлеге статья нигезендә төзелүче шартнамәдә, өч яшькә кадәрге баласы булган яшь гаилә гаризасы буенча, балага өч яшь тулганчы түләүләрне кичектереп тору шартлары каралырга тиеш.».

6. 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. Дәүләт ярдәмен финанслау

Дәүләт ярдәмен финанслау чираттагы финанс елына тиешле бюджетларны раслаганда Татарстан Республикасының Республика бюджеты һәм җирле бюджетлар исәбеннән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм халык депутатларының җирле Советлары билгели торган күләмнәрдә башкарыла. Дәүләт ярдәмен финанслау өчен законнарда тыелмаган башка чыганаклардан да акчалар җәлеп ителергә мөмкин.

Дәүләт ярдәме өчен бүлеп бирелгән финанс чаралары әлеге Законның 1 статьясының икенче өлешендә күрсәтелгән шартнамә нигезендә максатчыл

356
355 СОВЕТ

кулланылалар. Финанс чараларын юнәлдерү һәм куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен җибәрелгән финанс чараларын туплау, исәпкә алу һәм куллану өчен вәкаләтле оешма Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләтләр бирелгән банкта махсус счет ача.

Вәкаләтле оешма дәүләт ярдәме өчен бүлеп бирелүче акчаларның максатчыл кулланылышы өчен җаваплы була.

Яшь гаиләләр белән әлеге Закон нигезендә төзелгән шартнамәләрнең шартлары буенча кире кайтарылучы финанс чаралары, шулай ук торак урынын алмаштыру турындагы шартнамәләр буенча вәкаләтле оешма тарафыннан сатып алына торган торак урыннары яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәмен күрсәтүне дәвам итү өчен кулланылалар.».

7. Түбәндәге эчтәлектә яңа $10^1$ статья өстәргә:

«$10^1$ статья. Дәүләт теркәве өчен түләү

Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм әлеге Закон кысаларында аның буенча алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алган өчен түләү күләме хезмәт өчен түләүнең федераль законда билгеләнгән әч минималь күләмен тәшкил итә.».

8. 11 статьяда:

икенче өлештә «район, шәһәр яисә шәһәрдәге район администрациясенең» сүзләреннән соң «яисә вәкаләтле оешманың» сүзләрен өстәргә.

2 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 июне
№ 903